башкалардан алда йөгерүче балаларны үз урынына билгеләп куя.


***Атлар һәм көтүче***

Балалар атлар итеп билгеләнәләр, тәрбияче — көтүче. Ул, курай уйнаган хәрәкәтләр ясый-ясый, түбәндәге шигырь юлларын сөйли:

Курай уйныйм: та-ра-ра!
Атлар кай якка таба бара?
Атлар бара болынга,
Яшел чирәм ашарга.

Бу вакытта балалар, бер аякларын алга, икенчесен артка куеп, атлар кебек сикергәләп, мәйданчык буйлап йөриләр. Курай уйнаудан туктагач, «атлар» да туктап калалар, башларын селкеп торалар. Тәрбияче кабат курайда уйный һәм уен кабатлана

***Бергәләп өйрәник***



# ***Бакчадагы һөнәрләр***

## ***Әти-әниләр өчен методик ярдәмлек***

## ***(4-5 яшь)***

## Мәкальләр

* Хезмәт төбе — хәзинә.

* Эше барның ашы бар.

* Тирләп эшләсәң, тәмләп ашарсың.

* Бакча ясамый, алма булмый.

* Эшләп ашасаң, һәр ризык балдай татлы була.

* Агачны яфрак бизәсә, кешене хезмәт бизи.

* Тырышкан табар, ташка кадак кагар.

* Биш әйткәнче, бер эшлә.

* Сүзең белән мактанма — эшең белән мактан.

### *Табыышмаклар*

Сакалы бар, кашы юк,

Гәүдәсе бар, күзе юк.

Сакалын җирдән сөйри,

Бүлмә эчендә йөри. (Себерке.)

Шкафны да сөртә ул,

Идәнне дә җитешә. (Чүпрәк.)

Йөри-йөри паластан,

Эшли ул гел уттан.

Ул эшләсә, тузан юк,

Аның да тамагы тук.

(Тузан суырткыч.)

Аңа су да салалар,

Аңа чүп тә салалар.

Ул комны да, керне дә,

Ни салсаң да күтәрә. (Чиләк.)

### *Шигырь*

### *Һаҗирә апа*

Ә менә минем апа

Конфет-перәнник сата.

Ул эшләгән кибеттә

Бар ак күмәч тә, сөт тә.

Әйбер ала күп кеше

Олысы һәм кечесе.

Һәммәсе мактап китә,

Апамны хөрмәт итә.

Мөхәммәт Садри

### Хәрәкәтле уеннар

#### *Тизрәк урыныңа бар*

Уен балаларны урында ориентлашырга, ритм хисен тоярга, тигез хәрәкәтләр ясарга өйрәтә. Тәрбияче балаларны колоннага тезә, аннан соң алга басып, үзе балалар белүн бергү атлап йөри башлый. Балалар тигез атлап йөрсеннәр өчен, ул башта кул чаба һәм шул ук вакытта: «Бер-ике, бер-ике, бергә!» – дип әйтә, аннан соң, балаларның атлавына туры китереп, аларга таныш булган нинди дә булса бер җыр җырлый башлый. Җырның бер куплетын яки бөтенесен җырлап бетергәч, тәрбияче кисәктән генә: «Тизрәк урыныңа бар!» – дип кычкыра, һәм балалар барысы да урыннарына йөгерәләр. Тәрбияче